Гайфиева Г.Р.
Казан

# Р.ХАРИС ШИГЪРИЯТЕНДӘ ТОРМЫШ, ГОМЕР, ЯШӘҮ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

Аннотация: В статье рассматриваются стихотворения Рената Харриса, посвященные на раздумья о жизни, о ее быстротечности, о судьбе. Делается попытка выявления основных вопросов о жизни и путей их решения в творчестве поэта.

Тормыш, яшәеш, гомер агышы - әлеге төшенчәләр бер генә язучыны да битараф калдырмый. Язучылар, шагыйрьләр кешегә Ходай тарафыннан бирелгән бу илаһи вакытның асылына төшенергә һәм үзләренең бу дөньяда тоткан урыннанрын, кылган гамәлләренең ролен билгеләргә омтыла. Гомернең тиз узуы, аны туктатып булмавы, яшәүнең никадәр газаплы да, татлы да төшенчә булуы хакында уйлануларга Ренат Харис та үзенең шигъри юлларында киң урын бирә.

Р.Харисның лирик героеның гомер турында уйланулары гадәттә үзенең үткәнен, кылган гамәлләрен күздән кичерүгә нигезләнә. Үткәне турында уйланучы лирик герой – шагыйрь үзе ул. Ул әле үзалдына сорау куя:

Төннең шомы тиеп уянып
мин тын гына ятам уйланып...

Моңа кадәр ничек яшәдем?
ник сүз әйттем? Нигә дәшмәдем?

Шагыйрьнең шушы сорауга җавап эзләве шигырьдән шигырьгә күчә. Автор бу дөньяда үзенең мәсләген эзли. Әлеге эзләнү “Көмеш нур” шигырендә дә дәвам итә:

Утырам Идел ярында
гомер агышын тыңлап...

Биредә гомер, тормыш җыр белән чагыштырыла. Әлеге яшертен метафора ярдәмендә Р.Харис уйларының тирәнлеген дә күрсәтә:

Моңланып җырлап җибәрәм
тын гына, сүзсез генә...
Аңлыйм да кебек җырымны,
аңламыймын да кебек...

Лирик герой бу тормышның асылына төшенергә тырыша, аның күңеле бәргәләнә (“Күңелгә тулган көмеш чың бер көчәя, бер тына...”), ләкин сорауга бу шигырьдә җавап табылмый әле.

“Тормыш алда гына” шигырендә исә Р.Харис үткәненә күз ташлый да, үз-үзен әле бөтен яхшылык, бәхет-шатлык алда дип ышандырырга тырыша. Шагыйрьнең әлеге шигырендә дә башка бик күп әсәрләрендәге сыман үзенең үткәненә гаҗәпләнү белән канәгатьсезлек бергә үрелеп бара. Шагыйрь авырлыкларны җиңел генә үтеп чыга алуына гаҗәпләнсә, кылган ялгышларына үкенә:

Кайчакларда тетрәп-тетрәп куям –
ничек шулай атлый алганмын?!.
Упкын кыры буйлап йөргәнмен дә –
искитмәле – исән калганмын.

Бу хис шунда ук тормышның кайбер мизгелләрен сагыну, кире кайтару теләге белән алмашына:

Киләә кайчак кайбер эзләремә
кабат басып шунда каласы...
Олы мизгел өчен бар үткәнен
бирә ала адәм баласы.

Шигырьдә хисләр һәр дүртьюллык саен алмашына бара. Р.Харис бу турыда үзе дә искәртә: “Хисләремне хисләр алыштыра...” Алга таба шагыйрь үткәндәге ялгышлары өчен үкенү кичерә. Әлеге үкенеч үзеңнең данлы исемең турында кайгырту белән генә бәйле түгел, автор бу гамәлләр киләчәк буынга зыян салмасын иде дип борчыла:

Кайберләре йөзне кызартырлык.
Андыйларны килә күмәсе –
тузаныны хәтта бөртеге дә
килер буыннарга тимәсен.

Шигырь киләчәккә өмет, авторның үзен һәм укучыларын тормышның матур мизгелләре әле алда булуына ышандыру белән тәмамлана. Гомумән, Р.Харис киләчәккә өметен югалтмый, ышаныч белән карый һәм үз-үзенә үтенеч белән мөрәҗәгать итә (читләтеп, укучысына да дип аңларга җирлек бар):

алга кара – тормыш алда гына,
ян-як – гыйбрәт, артта – үкенеч...

“Җилләрдә җилфердәдем...” шигырендә, киресечә, шагыйрь үткәндәге кылган гамәлләре өчен горурлык хисе кичерә. Бу шигырьне үткән гомергә нәтиҗә ясау буларак кабул итәргә мөмкин. Р.Харис, җил, яңгыр, кояш, көз, яз кебек төшенчәләргә метафорик мәгънә салып, үзенең авырлыклар белән көрәшүен тасвирлый. Алай гына да түгел, ул тормышның үзе белән сугышка чыга (“Тормыш белән сугыштым”). Без югарыда карап үткән шигырьләрдә автор тормышның кире кайтарып булмаслык төшенчә, аның тиз үтеп китү, үзеннән соң горурланырлык һәм үкенерлек мизгелләр калдыруы хакында гына уйланса, бередә аны чикләүче төшенчә Үлем дә пәйда була. Шагыйрь “Үлемгә каршы - әзер” дигән катгый карар чыгара.

Шагыйрь яшәешне үзгәртеп булмасын яхшы аңлый. Икенче бер шигырендә ул тормышны сыер белән чагыштыра. Күрәсең, әлеге хайванның кирелегенә, шул ук вакытта үҗәлегенә нигезләнә. Р.Харис тормышны һәм сыерны тәңгәлләштереп мөрәҗәгать итә – тормыш-сыер:

Без дигәнчә бармый тормыш-сыер:
алга кусаң – артка борыла...

Алдагы юлларда үз тормышы мисалында шагыйрь әлеге юлларның дөреслеген раслый: ул якты хисләрен белдерергә омтыла, киресе килеп чыга; елмаерга теләсә, “гел елмайган йөзем бик еш чытык, ә күземнән утлы яшь ага”. Шигырь ахырында тагын сыер образына мөрәҗәгать итеп нәтиҗә ясый:

Без дигәнчә бармый тормыш-сыер...
Иртә язның якты кырына
куган саен,
печән исе сеңгән
тынчу абзарына борыла.

Биредә “иртә язның якты кыры” шагыйрь күрергә теләгән киләчәк, ә “печән исе сеңгән тынчу абзар” чынбарлык кебек аңлашыла.

Р.Харис яшәүне “гомер сөрү” дип атый. Шагыйрь тормышны кыр-басу белән чагыштыра, ә кешенең кылган гамәлләре әнә шул кара җирне “сөрүе”:

...Һәм без гомер сөрәбез...
Сөрә-сөрә күрәбез...

Биредә автор үз исеменнән генә сөйләми, ә үткәннәргә “без” дип бөтен кешелек дөньясы исеменнән нәтиҗә ясый: бөтен кылган гамәлләр авторда канәгатьсезлек уята:

пычрак икән тирәбез,
тозсыз икән өйрәбез,
комнан аркан үргәнбез,
салкын суга өргәнбез,
кемнәрнедер кызганып,
салып ыштан биргәнбез...

Кешеләрнең бөтен кылган гамәлләренең нәтиҗәсез, юкка, бушка булуына шагыйрьнең күңеле әрни. Биредә гомер итү, тормыш аерым бер кешенең туганнан алып үлемгә кадәр үткән юлы гына булып калмыйча, тулы бер илнең, халыкның тормышы дәрәҗәсенә күтәрелә. Р.Харис халыкның “көлгә әйләнүенә” түзә алмыйча, аны бердәмлеккә өнди:

Әверелик илгә без,
тузан булмыйк җилдә без,
таза әле җилкәбез –
әверелик илгә без!

Шул рәвешле Р.Харис шигъриятендә тормыш, яшәеш, гомер кебек төшенчәләр хакында уйлануларга киң урын бирә. Шагыйрьнең әлеге юнәлештә язылган күп әсәрләрендә үзәктә үткәннәрне искә төшерү, кылган ялгышлыклар өчен үкенү, тормышка нәтиҗә ясау урын ала. Шулай ук ул, кешенең бөеклеген, бу җиһанда үз урынын табарга көче барлыгын ассызыклап, укучының күңелендә өмет уятырга тырыша.

Кулланылган әдәбият:


1. Харис Р. Тоткасыз ишек: Шигырьләр, поэмалар. / Ренат Харис – Казан: Татар.кит.нәшр., 1999. – 192 б.
2. Харис Р. Хисемнең исеме: Шигырьләр, поэмалар. / Ренат Харис – Казан: Татар.кит.нәшр., 1996. – 255 б.
3. Харис Р. Хәл-әхвәл: Шигырьләр, поэмалар. / Ренат Харис – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. – 208 б.
4. Хәсәнова Ф. Шагыйрь һәм заман: Хәзерге татар шигърияте (1985-2009): Монография / Ф.Хәсәнова. – Казан: РИЦ МОиН, 2010. – 296 б.